ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИE** **КАРАР**

от 29.01.2016 г. Казань № 10-3/кс

«Тепло-ЭнергоСервис +» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять тарафыннан җибәрелә торган кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларында кайнар суга тарифны билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ санлы Федераль законга, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Тепло-ЭнергоСервис +» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять тарафыннан җибәрелә торган кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларында кайнар суга тарифларны әлеге карар кушымтасы нигезендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2016 елның 1 мартыннан алып 2016 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. «Тепло-ЭнергоСервис +» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 санлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы айга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 29.01.2016 № 10-3/кс
карарына кушымта

Календарь чорларын бүленгән «Тепло-ЭнергоСервис +» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җибәрелә торган кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларында кайнар суга тарифлар

<table>
<tr><th rowspan="3">№ п/п</th><th rowspan="3">Муниципаль берәмлек, кайнар су белән тәэмин итүче оешма атамасы</th><th colspan="4">Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында кайнар суга тариф (ике компонентлы)</th></tr>
<tr><th colspan="2">Салкын суга компонент, сум/куб.м</th><th colspan="2">Җылылык энергиясенә компонент, сум/Гкал</th></tr>
<tr><th>с 01.03.2016 по 30.06.2016</th><th>с 01.07.2016 по 31.12.2016</th><th>с 01.03.2016 по 30.06.2016</th><th>с 01.07.2016 по 31.12.2016</th></tr>
<tr><td></td><td>Бөгелмә муниципаль районы</td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>1</td><td>«Тепло-ЭнергоСервис +» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять</td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>1.1</td><td>Халык (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән)*</td><td>28,74</td><td>30,28</td><td>1594,07</td><td>1663,78</td></tr>
<tr><td>1.2</td><td>Башка кулланучылар (тарифлар НДСтан тыш күрсәтелгән)</td><td>24,36</td><td>25,66</td><td>1350,91</td><td>1409,98</td></tr>
</table>

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 маддәсе 6 пунктын гамәлгә ашыру максатыннан чыгып бүлеп бирелә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештыру һәм җайга салу бүлеге